ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

11.06.2021 Олы Кайбыч ав. № 209

Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 29 маендагы 254, 255 номерлы карарларына үзгәрешләр кертү турында

Үзгәрешләр кертү зарурлыгына бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Муниципаль милектәге җирләрдә аукцион үткәрмичә генә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга шартнамә төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 29 маендагы 255 номерлы карарының 3 нче кушымтасы) (алга таба - Регламент) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Регламентның 2.8 пунктыннан 5 пунктчаны төшереп калдырырга;

1.2. 2.9 пунктына түбәндәге эчтәлекле 4 пунктча өстәргә:

«4) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурыч булу».

2. Җир эшләрен башкаруга ордер (рөхсәт) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 29 маендагы 254 номерлы карарының 15 нче кушымтасы) (алга таба - Регламент) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2.1. Регламентның 2.8 пунктыннан 5 пунктчаны төшереп калдырырга;

2.2. 2.9 пунктын түбәндәге эчтәлекле 4 пунктча өстәргә:

«4) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурыч булу»

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге http:// kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең төзелеш һәм ТКХ буенча урынбасары Ф.Ш. Әхмәтовка йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы
Башкарма комитет
Җитәкченең беренче урынбасары Э. Х. Заһидуллина